**Муниципальное бюджетное образовательное учреждение**
**«Чертушкинская начальная школа-детский сад**
**Новошешминского муниципального района РТ»**

| **«Рассмотрено»**<br>Руководитель ШМО учителей начальных классов<br>_______Зарипова.Л.А.<br>Протокол № 1 от «27» августа 2021 г. | **«Принято»**<br>на заседании педагогического совета<br>Протокол №1 | **«Утверждаю»**<br>Директор МБОУ Чертушкинская НОШ<br>__________ Г.Т.Мазитова<br>Приказ №16 от «27» августа2021г. |
|---|---|---|

# Рабочая программа
# по предмету «Родной татарский язык»
# 1-4 классы
# Срок реализации - 4 года.

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1-4 сыйныфлары өчен татар теленнән эш программасы башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә *туры китереп*,“ Татар телендә белем бирүче гомумбелем оешмалары өчен туган тел (татар теле) фәне буенча үрнәк эш программасы: 1-4 нче сыйныфлар”га *нигезләнеп*төзелде.

«Перспектив башлангыч мәктәп»УМК дәреслекләрнең фән линиясе тормышка ашырыла.

**Дәреслекләр:**

| *Дәреслек исеме* | *Сыйныф* | *Авторлар* | *Нәшрият* |
|---|---|---|---|
| Әлифба. Дәреслек. 1 нче сыйныф | 1 | И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Р.Р. Шәмсетдинова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Татар теле. Дәреслек. 1 нче сыйныф | 1 | И.Х.Мияссарова, Ч.М.Харисова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Татар теле. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 2 нче сыйныф. | 2 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| Татар теле. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 3 нче сыйныф. | 3 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф - Вакыт” |
| Татар теле. Дәреслек. 1нче кисәк.2 нче кисәк. 4 нче сыйныф. | 4 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |

Эш программасы 445 сәгатькә исәпләнгән (1 нче сыйныф-99 сәгать, 2 нче сыйныф–102 сәгать, 3 нче сыйныф- 136 сәгать, 4 нче сыйныф- 102 сәгать).

## Уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

### 1 нче сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр**

Укучыда формалашачак:

- туган ил, халкың һәм тарих өчен горурлык хисе кичерү;

үзеңнең милли һәм этник яктан кая керүеңне аңлап, рухи кыйммәтләр булдыру;

- дөньяга, аның табигать, халык, мәдәният, дин бергәлегенә карата тулы, социаль юнәлештәге караш формалаштыру;
- башка фикерләргә дә хөрмәт белән карарга өйрәнү;
- башкаларның хис – тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы – шатлыгын уртаклашу;
- үзең өчен җавплылык хисе һәм мөстәкыйллелекне үстерү;
- өлкәннәр һүм яшьтәшләрең белән төрле социаль ситуацияләрдә хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерү

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

- *бәхәсле ситуацияләрдән чыгу юлын табу сәләтен булдыру;*
- *куркынычсыз, сәламәт яшәү рәвеше алып бару,*

*материаль һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл караш формалаштыру.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

Укучы өйрәнәчәк:

- укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләргә һәм формалаштырга;
- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнергә;
-дәреслек белән эш итә белергә;
- хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, экиятне) сәнгатьле итеп укырга;
- этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап укырга;
- текста очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә;
-текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирергә;
-укытучының сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белергә;
- информация табу өчен төрле эзләү төрләре , җыю, эшкәртү, анализ, оештыру, тапшыру кулланырга.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

- *предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белергә;*
- *укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген кыскартып яки, тулыландырып сөйли белергә;*
- *итә белү (линейка, карандаш, бетергеч…) һәм өстәмә чаралар (информацион һәм коммуникацион технологияләр, белешмә әдәбият һ.б.) куллана белергә;*
- *эш сыйфатына бәя бирә белергә;*
-*уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белергә.*

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

Укучы өйрәнәчәк:

- эшчәнлек өчен эш урынын әзерләргә;
- бер үк сорауга төрлечә җавап бирү мөмкин икәнлегеен аңларга;
--үз фикереңне дәлилләү өчен уку китабыннан мисалларга мөрәҗәгать итәргә;
- үзанализ һәм үзбәя булдырырга.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*2) укытучы ярдәме белән уку проблемасын табарга һәм формалаштырырга;*
*3) укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга;*
*4) укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерергә;*
*5) эш барышында гади генә эш кораллары белән эш итәргә.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

Укучы өйрәнәчәк:

- иллюстрация белән эш вакытында үзеңнең фикереңне, күзаллауыңны әйтергә өйрәнергә;
- үз позициясен дәлилләү өчен кагыйдә, таблицалар, модельләрдән файдаланырга;
- партадашы белән эшләргә:
- эшне үзара бүлешергә;
-чылбыр тәртибендә эшләргә;
- башкаларның сөйләмен тыңларга һәм аңларга;
- тормыш тәҗрибәсен кулланырга.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

- *уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;*
- *күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;*

*- күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга;*
*- сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә.*

**Предмет нәтиҗәләре**

**1нче сыйныфны тәмамлаганда,** татар телен өйрәнү нәтиҗәләре:
укучылар өйрәнәчәк:
-авазлар һәм хәрефләр;алфавит, сузык һәм тартык авазлар, аларның бүленеше, иҗекләрне;
-сүзләрне иҗекләргә бүлергә һәм юлдан-юлга иҗекләп дөререс күчерергә, җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта,сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес куярга;
-гади җөмлә төрләре: хикәя, сорау, өндәү җөмләләрне таный белергә;
-кеше исемнәрен,фамилияләрне,шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәрефтән язарга;
- дөрес һәм матур итеп күчереп яза белергә, 20-25 сүзле текстны диктант итеп язарга;
-гади сүзләргә иҗек-аваз анализы ясарга,ъ,ъ,я,ю,е хәрефләре кергән сүзләрнең аваз һәм хәреф санын әйтергә.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*-укучыларда телдән һәм язма сөйләмгә карата, кешенең гомуми культурасы күрсәткече буларак, уңай караш формалашу.*
*-татар әдәби теленең төрле нормалары (орфоэпик, лексик һәм грамматик), сөйләм әдәбе кагыйдәләре турында башлангыч белем алу;*
*- аралашу вакытында куелган максат, бурыч һәм чаралардан чыгып, өйрәнгән материалны кулланырга өйрәнү;*
*- катлаулы булмаган монологик сөйләм һәм язма текстлар төзегәндә, коммуникатив бурычларны уңышлы үтәү өчен, туры килгән тел чараларын сайлау.*

**Төпчор** ахырына балалар өйрәнәчәк:
1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала / ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;
- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын аңлый белергә.
- сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп билгели бара, берсен аерып алып аңа характеристика бирергә;
- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын кулланырга;
- сүзне иҗекләргә бүлергә;

- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укырга;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укырга;
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә үзгәртергә;
- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне төзи һәм анализларга;
- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан файдалана алырга;
- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр язарга;
- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын үтәргә;
- тактлапязгандакулчугымускулларыкиеренкелегенйомшартырга;
- күчерепязгандаһәм диктант вакытларында җөмләләрнеһәмүз исемнәрен дөрес язарга;
- бизәк-бордюрларясый ала белергәтиешләр.
- алгоритм буенчасүзләрдәязмахәрефләрнеңһәмаларнытоташтырусызыкларын язарга;
- тактлапязгандакулчугымускулларыкиеренкелегенйомшарухаләтебеләнчиратлаштырабелергә;
- язмаһәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчерепязарга, әйтепяздыраторгантекстны язарга.

Грамотага өйрәтүнең ***әлифбадан соңгы чоры***нда беренче сыйныф укучылары <u>өйрәнәчәк</u>:
1. Тугантелнеңсөйләмтөзелешенаңлый, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләренобразлыкүзалларга;
- татар алфавиты басма һәмязмахәрефләренең график системасын;
- һәрхәрефнең элемент формаларын;
- дөресутыруһәмязмаәсбапларныкуланукагыйдәләренбелергә.
- үзенәгенәхастемпта басма һәмязматекстларныофоэпикнормаларга туры китерепукырга;
- текстнынңаерымберөлешләренсөйләргә (2 — 3 җөмлә белән) ;
- укылган текст эчтәлегебуенчабирелгәнсорауларгаҗавапбирергә;
- тыңлангантексткаисем кушарга;
- О, ө хәрефләренберенчеиҗектә генә язарга;
- әйтмәһәмязмасөйләмне тел берәмлекләренеңтөзелешетурындаберенчесыйныфукучыларындаформалашканкүзаллаунигезендәанализлауһәмтиешлесимволларбеләнмодельләштерергә;
- тыныш билгеләренәигътибаритеп, иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешлеитепукуалымнарынкулланырга;
- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын тормышка ашырырга;
- татар теленеңпозиционпринцибынанигезләнеп, [гь] [кь] авазларын язуда белдерү турында үзләштергән белеем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә;
- сүзләрне авазларга таркатырга; авазларны сүздәге тәртиптә әйтергә; сузыкһәмтартыкавазларны һәм аларның хәрефләрен аерыптаный белергә; калын һәм нечкәсузыкларныдөресәйтергә; сузыкавазһәмаларныңхәрефләренәкарап, калынһәмнечкә әйтелгән сүзләрне танырга; сүзләрнеиҗекләргәбүлергә;җөмләләрнесүзләргәтаркатырга. Башһәмюлхәрефләрен, аларны тоташтыручысызыкларныһәмсүзләрнеачыкитеп, бозмыйча язарга;
- басма, кулданязылганхәрефләрбелән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язарга;
- әйтелешебеләнязылышы туры килгәнсүзләрне, шундыйсүзләрдәнтөзелгән 3-5 сүзлеҗөмләләрнеишетепязарга;
- җөмләнеңберенчесүзен баш хәрефбеләнбашлап, җөмләбеткәч, ноктакуепязарга.

*<u>Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*

*- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзергә;*
*- сыйныфта телдән җыр, шигъри куплетлар, мәзәк, әкиятуйлапчыгарырга.*
*- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтербуенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгәналгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендәдә сүзләрне өзмичә язу күнекмәләрен үзләштерә һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә;*
*-график хаталарны төзәтергә һәм каллиграфик язусыйфатын камилләштерү эшләрен;*
*-тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштырырга.*

## 2 нче сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр**
Укучыда формалашачак:
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

*Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*
*- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;*
*- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*
*“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**
***Танып-белү УУГ:***
Укучы өйрәнәчәк:
-“Дөрес яз”, “Дөрес әйт” сүзлекләре белән эшләргә, кирәкле сүзләрне эзләп табарга;
- дәреслектә ориентлаша белергә;
- шартлы билгеләрнең телен белергә;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәргә;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәргә;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белергә.
*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*- объектларны чагыштырырга, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләргә;;*
*- төп мәгълүматны аерырга, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белергә;*
*- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштырырга;*
*- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәргә.*

***Регулятив УУГ:***
Укучы өйрәнәчәк:
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алырга, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерергә;
- тормыш тәҗрибәсен кулланырга;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештырырга, нәтиҗәле эш алымнарын таба белергә;*

*- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белергә;*

*- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белергә.*

***Коммуникатив УУГ:***

Укучы өйрәнәчәк:

- үз позициясен дәлилләү өчен кагыйдә, таблицалар, модельләрдән файдаланырга;
- партадашы белән эшләргә:
- эшне үзара бүлешергә;
-чылбыр тәртибендә эшләргә;
- башкаларның сөйләмен тыңларга һәм аңларга;
- тормыш тәҗрибәсен кулланырга.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;*

*- күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;*

*- күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга;*

*- сөйләмнең диалог формасын үзләштеррегә.*

**Предмет нәтиҗәләре**

**Фонетика һәм орфоэпия**

Укучы өйрәнәчәк:

-“Татар теле” дәреслегенең төзелешен;
- татар теленең төп сүзлекләрен;
- сүздәге сузык авазларның калын яки нечкә әйтелешен андагы сузык авазларга карап аеруны;
- О хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә язылуын, калган иҗекләрдә , [о]авазы ишетелсә дә ы хәрефе язылуын;рус сүзләрендә о хәрефе төрле иҗекләрдә язылуны;
- э, е хәрефләре нечкә сузыкларны белдеруен, язуда[э]авазын белдерүен, сүз башында э хәрефе язылуны;
- татар теленең үз сүзләрендә э,е хәрефләре кыскарак әйтелә торган [э]авазын, рус телендә сузыбрак, киңрәк әйтелә торган [э]авазын белдерүне;
- кайбер сүзләрдә ( маэмай, тээсир,тээмин) [э]авазының әйтелешне;
- сузык аваз иҗек төзүне;
- һәр иҗектә сузык аваз бер генә булуны;
- иң кечкенә иҗек бер сузыктан торуны;
- сүзнең бер хәрефен иҗек булса да, юл ахырында калдырырга да, яңа юлга күчерергә дә ярамауны;
- тавышсыз хәрефләр(ъ,ь) үзләреннән алдагы хәрефләреннән аерып күчерелмәүне;
- *йо, йө* кушылмалары сүз башында гына язылуны;
- *йо* кушылмасы – калын укыла торган сүзләрдә, йө кушылмасы нечкә укыла торган сүзләрдә язылуны;
- сүз башында булмаганда , й хәрефе сузык авазлар артында гына язылуны;
- калынлык билгесе (ъ) иҗекнең нечкә әйтелешле иҗекләрдән к. г хәрефләренең калын укылышын күрсәтүне;
- Ъ хәрефе калын иҗекләрдән соң я, ю,е хәрефләре алдыннан килгәндә , тартыкларны аерып укырга кирәклекне күрсәтүне.
- “Эчтәлек” битендә ориентлаша алышырга;
- сүздән авазны аерып алу, аңа характеристика бирүне;

- сүзгә аваз-хәреф схемасын төзүне;
- калын (нечкә) сузык авазларны икеләнүсез аеруны, аларга анализ ясауны;
- хәрефләрне сүзләрдә дөрес язуны.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*-ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә алырга*

**Графика**

Укучы өйрәнәчәк:

- Татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес әйтеп, яттан белергә, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштырырга.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*- кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана алырга.*

**Сүз (морфология, сүз төзелеше (морфемика)**

Укучы өйрәнәчәк:

- сүз һәм җөмләнең аермасын;
- сүз тамырының мәгънәле кисәк булуны;
- татар телендә сүз тамырының сүз башында булуын, үзгәрмәвен, тамырда сүзләрнең, яңа мәгънә белдерүне;
- сүз ясагыч кушымчаларның сүзнең мәгънәсен үзгәртүне;
- кем? нәрсә? сораулары ярдәмендә предметны белдерә торган сүзләрнең үзлеген белергә;
- кеше исемнәрен һәм фамилияләрен һәрвакыт баш хәрефтән язарга;
- шәһәр, авыл, елга, күл исемнәрен баш хәреф белән язарга;
- эш- хәрәкәтне белдерә торган сүзләр җөмләдә нишли? нишлиләр? сорауларына җавап бирүен;
- билгене белдерә торган сүзләрнең нинди? кайсы? сорауларына җавап бирүне.
- *сүз, сүзтезмә, җөмләләрне аера белергә;*
- *сүзтезмәләр төзеп яза белергә;*
- *татар алфавитын төгәл, хәреф исемнәрен дөрес әйтеп, яттан белергә, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштырырга;*
- *тамырдаш сүзләрне аера һәм аларның тамырын билгели белергә;*
- *сүзнең тамырын һәм сүз ясагыч кушымчаларын билгеләргә; тамырдаш сүзләр ясап язарга, сүзнең тамырын һәм сүз ясагыч кушымчаларын билгеләргә; тамырдаш сүзләр ясап язарга;*
- *текст буенча сорауларга җавап яза алырга;*
- *кем? нәрсә? сораулары ярдәмендә предметны белдерә торган сүзләрнең үзлеген белергә;*
- *ялгызлык исемнәрен дөрес яза белергә;*
- *җөмләдә эш-хәрәкәтне белдергән сүзләргә сорау куярга, аларны билгеләргә һәм җөмләдәге ролен гамәли күзәтергә;*
- *җөмләдә билгене белдерә торган сүзләргә сорау куярга, аларны билгеләргә һәм җөмләдәге ролен гамәли күзәтергә.*

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

- *сүздән авазны аерып алырга, аңа характеристика бирергә;*
- *сүз, сүзтезмә, җөмләләрне аера белергә;*
- *тамырдаш сүзләрне аера һәм аларның тамырын билгели белергә.*

**Җөмлә (синтаксис)**

Укучы өйрәнәчәк:

- сөйләмне җөмләләргә аерырга;
- *җөмләнең баш кисәкләрен табарга.*

- җөмләнең баш кисәкләрен табарга, җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләргә;
<u>*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*</u>
*- әйтелү максатына карап, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен куярга;*
*- җөмләнең баш кисәкләрен табарга.*
*- баш кисәкләрен табып, сызыклар белән билгеләргә.*

<u>**Бәйләнешле сөйләм**</u>
<u>Укучы өйрәнәчәк::</u>
- текстның өлешләрен: башламы, төп , йомгаклау өлешләрен табарга;
<u>*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*</u>
*- текст буенча сорауларга җавап язарга;*
*- текстны өлешләргә бүлеп, аларга исем кушарга.*

<u>**3 нче сыйныф**</u>

<u>**Шәхси нәтиҗәләр**</u>
<u>Укучыда формалашачак:</u>
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың,уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү.

<u>*Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*</u>
*- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;*
*- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую).*

<u>**Метапредмет нәтиҗәләр**</u>

<u>***Танып-белү универсаль уку гамәлләре:***</u>
<u>Укучы өйрәнәчәк:</u>
- дәреслектә ориентлаша белергә;
- шартлы билгеләрнең телен белергә;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәргә.
<u>*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*</u>
*- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белергә;*
*- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштырырга;*
*- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәргә.*

<u>***Коммуникативуниверсальукугамәлләре:***</u>
<u>Укучы өйрәнәчәк:</u>
- күршеңбеләнхезмәттәшлек итәргә;
- үзфикереңнеһәмпозицияңнеформалаштырырга;
- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килергә;
- сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә.
<u>*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*</u>
*- күршеңнең нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә сораулар бирергә;*
*- күршеңнең эш-гамәлләрен контрольгә алырга.*

<u>***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***</u>
<u>Укучы өйрәнәчәк:</u>
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;

- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алырга, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерергә.
*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*- тормыш тәҗрибәсен кулланырга;*
*- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белергә;*
*- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә.*

**Предмет нәтиҗәләре**

**Фонетика һәм орфоэпия**
Укучы өйрәнәчәк:
-сүзгә фонетик анализ ясарга, иҗекләргә бүләргә,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгарга;
-үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштырырга.
*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*-сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны икеләнүсез аеру, бирелгән теориягә таянып, аларга анализ ясау;*
*- бирелгән аваз схемасына,характеристикага тиешле авазлар, сүзләр сайларга.*

**Лексика.**
Укучы өйрәнәчәк:
-сүзнең мәгнәле кисәкләрен, тамыр һәм кушымча, ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны аера һәм аларны сүзне кулланганда файдалана белергә;
-тамырдаш сүзләрне икеләнүсез аерырга.
*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*-сүзләрнең төзелешен модель итеп күрсәтә белергә, модель үрнәгендә яңа сүзләр ясарга.*

**Морфология**
Укучы өйрәнәчәк:
-сүз төркемнәре: исем, татар телендә килешләр һәм аларның сораулары, исемнәрнең килеш белән төрләнешен;
- фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары, фигыльләрнең барлык һәм юклык төрләре, фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше, хикәя фигыльнең заман белән төрләнешен;
- сыйфат дәрәҗәләрен;
- зат алмашлыкларының килеш белән төрләнешен;
-кисәкчә, кисәкчәнең сөйләмдәге роле, язылышын;
- бәйлекләрнең сөйләмдәге роле, язылышын.
*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*-сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен танырга, аерырга(исемнең – санын, тартым кушымчалары булганда – затын, килешен, фигыльнең заманын, затын, санын).*

**Синтаксис**
Укучы өйрәнәчәк:
-җөмләнең баш кисәге, ия, хәбәрне;
-җөмләнең иярчен кисәкләрен.

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*- җөмләне анализлау: әйтү максаты, интонация буенча төре, баш һәм иярчен кисәкләрне табарга.*

**Бәйләнешле сөйләм**

Укучы өйрәнәчәк:

- әзер яки бергәләп төзелгән план буенча 70-85 сүзле тексны изложение итеп язарга, текстның темасын һәм фикерен чагылдыра алырга, кызыл юлны сакларга;

- сөйләгәндә һәм язганда, текст өлешләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдырырга;

*Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*- хикәяләү, тасфирлама, фикер йөртү тибындагы текстларны аерырга, төзи белергә һәм кечкенә күләмле текстлар язып куярга;*

*-шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картина һәм рәсемгә таянып сочинение язарга, сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдырырга.*

## 4 нче сыйныф

### Шәхси нәтиҗәләр

Чыгарылыш сыйныф укучысында формалашачак:

- физик һәм психик сәламәтлекне саклау;
- татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш;
- тел аша әйләнә-тирә тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;
- фикерләү сәләтен үстерү;
- үзенә һәм башкаларга бәя бирүенә, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү;
- татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
- дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
- үз уңышларың,уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
- нормалардан тайпылышны күрү;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу; предметара нәтиҗәләре:
- гомуми уку кунекмәләре һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу сәләтләре;
- үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү күнекмәләре.

*Чыгарылыш сыйныф укучысы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*

*- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш һәм аны яхшы өйрәнү теләге;*

*- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;*

*- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*

*- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр.*

### Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:

- тел чараларының төрле жанрдагы әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен күрә белергә;
- тел материалын уку материалы белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәткә;
- татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белергә,сөйләм барышында ике тел чараларын бутамаска;
- татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән лексик чараларны аеруга игътибар юнәлтергә;
- татар теленнән алган белемне башка фәннәрне үзләштерүдә файдалана белергә.

*Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

*- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белергә;*

*- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләргә, аларны чишү өчен*

*алгоритм булдырырга;*
*- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләргә;*
*- төп мәгълүматны аерырга, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белергә;*
*- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар кулланырга.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңларга, аңа туры килерлек җавап бирә белергә;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзергә;
- аралаша белү сәләтен үстерергә (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белергә;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкарырга;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белергә.

<u>**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**</u>
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белергә;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белергә;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белергә;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белергә;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белергә;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштырырга;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белергә.

<u>**Предмет нәтиҗәләре**</u>
**Тел системасы**
**Фонетика, орфоэпия һәм графика**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- аваз һәм хәрефләрне аерырга;
- ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә алырга;
- хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана алырга.

*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясарга, сүзгә ясалган фонетик-график анализның дөреслеген бәяләргә;*
*- үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяләргә;*
*- сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә алырга.*

**Сүз *төзелеше (морфемика)***
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга;
- сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга.
*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерергә һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге алырга.*
**Лексикология**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>

- мәгънәсе ачыклану таләп ителә торган сүзләрне табарга;
- текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга.
*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*-текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге алырга.*
**Морфология**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләндерергә;
- сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен;
- фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен.
*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясарга һәм аның дөреслеген бәяләргә, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табарга.*
**Синтаксис**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга;
- сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга;
- җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга;
- җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә;
- тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә.
*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик*
*- анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аерырга.*
**Орфография һәм пунктуация**.
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга;
- сүзләрнең дөрес язылышын орфографик сүзлек буенча ачыкларга;
- 80–90 сүзле текстны дөрес итеп күчереп язарга;
- өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 70–80 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга;
- үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстны тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә.
*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларны аңларга, аерым орфограммаларга мисаллар сайларга, текстлар төзегәндә орфографик һәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртергә, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенергә һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыкларга.*
**Сөйләм үстерү**
<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:</u>
- аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга;
- көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга;
- аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә;
- текстка исем бирергә;
- укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә;
- аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга.

*<u>Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:</u>*
*- тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзергә, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләргә, сөйләмнең сурәтләү, хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзергә, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерергә һәм төзәтергә, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын табарга, хаталы текстларга төзәтмә кертергә, төрле төрдәге изложение яки сочинение язганда, эшне эзлекле алып барырга, аны тикшерергә һәм бирелгән үрнәк белән чагыштырырга, уку бурычларының дөреслеген бәяләргә, үз текстын, аралашу максаты һәм шартыннан чыгып, чыганак (беренчел) текст белән чагыштырырга, электрон чыганаклардан файдаланганда, тел нормаларының үтәлешен сакларга.*

**<u>Укыту предметының төп эчтәлеге</u>**
**<u>1сыйныф</u>**

| № | Бүлекләр-нең исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге | Сәгать-ләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Грамотага өйрәтү** | | **63** |
| 1.1 | **Грамотага әзерлек чоры** | Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү.Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату. Дәфтәр битендә ориентлашу. Язу сызыгы, язуның башлангыч ноктасы. Структур берәмлек буларак кулланылган сызык элементлары.Алгоритм буенча сызык элементларын язу. | **12** |
| 1.2 | **Әлифба чоры, яки төп чор** | Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү. Язуда өч төрле (аскы,урта,өске) тоташтыру алымы. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сызыкларын өзмичә ритмик язуны булдыру , дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру. Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу. Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне диктант итеп язу | **49** |
| 1.3 | **Әлифба-дан соңгы чор** | Алфавитны дөрес язу,уку.Аерым сүзләр белән җөмләләр төзеп язу. Текстны дөрес итеп күчереп язу | **2** |
| 2 | **Телне системалы өйрәнү** | | **36** |
| 2.1 | **Морфоло-гия** | Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Предметны белдерүче сүзләр. ярдәмче сүзләр- Эш- хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Билгене белдерүче сүзләр. | **12** |
| 2.2 | **Синтак-сис** | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән | **5** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую. | |
| 2.3 | **Орфогра-фия** | Орфография кагыйдәләре белән танышу: сүзләрдә э (е) хәрефенең язылышы; татар сүзләрендә о һәм ө хәрефләренең сүзләрнең беренче иҗегендә генә язылуы. Е, ю, я хәрефләре. Калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләре. Калын тартыклар [гъ], [къ] , аларны хәрефләр белән билгеләү. Сонор тартыклар [м], [н], [ң]. Тартыклар [в], [w], аларны хәрефләр белән билгеләү. | **13** |
| 2.4 | **Бәйлә-нешле сөйләм.** | Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Сөйләм, аның тормыштагы роле. | **6** |
| **Барлыгы** | | | **99** |

## 2 сыйныф

| № | Бүлекләр-нең исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге | Сәгать-ләр саны |
|---|---|---|---|
| *2* | **Телне системалы өйрәнү** | | |
| *2.1* | **Фонетика һәм орфоэпия** | Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Сингармонизм.Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр. Аваз һәм хәрефләрне аеру. Сузыкавазлар.<br>Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.<br>Яңгырау һәм саңгырау, парлы һәм парсыз тартыклар.Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр.Татар теленә генә хас булган [w], [гъ], [къ], [х], [ч]; [ж], [ң], [h] авазлары. | **41** |
| *2.2* | ***Графика*** | *Е, ю, я*хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу.Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы.Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.<br>*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку.<br>Татар алфавиты: хәрефләрнең тәртибен һәм исемен яттан белү. Сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү. | **2** |
| *2.3* | ***Лексика*** | Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. .<br>Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. Татар телендә исем һәм сыйфатның синтаксик бәйләнеш үзенчәлеге.<br>Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану.Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану. | **40** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, синонимнар сүзлеге, антонимнар сүзлеге. | |
| *2.4* | ***Синтаксис*** | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую.<br>Сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөрес әйтелеше.<br>Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).<br>Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү. | **8** |
| *2.5* | ***Орфогра-фия*** | Орфография кагыйдәләре белән танышу: сүзләрдә э (е) хәрефенең язылышы;татар сүзләрендә о һәм ө хәрефләренең сүзләрнең беренче иҗегендә генә язылуы. Е, ю, я хәрефләре. Калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләре. Калын тартыклар [гъ], [къ] , аларны хәрефләр белән билгеләү. Сонор тартыклар [м], [н], [ң].Тартыклар [в], [w], аларны хәрефләр белән билгеләү. | **4** |
| *2.6* | ***Бәйләнешле сөйләм*** | Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Өч-дүрт җөмләдән торган хикәя төзеп язу. Рәсем буенча кечкенә хикәя төзү.Шигырь, табышмак, мәкальләрне ятлап хәтер диктанты язу.<br>Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасынбилгеләү, төп фикерен табу.Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.<br>Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү.Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау.Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.<br>Текст.Текстның темасын, төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү.Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре.<br>Сөйләм этикасы белән таныштыру.<br>. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.<br>Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.<br>Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә. | **7** |
| **Барлыгы** | | | **102** |

## 3 класс

| № | Бүлекләр-нең исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге | Сәгать-ләр саны |
|---|---|---|---|
| *2.* | **Телне систематлы өйрәнү** | | |
| *2.1* | **Фонетика һәм** | Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. | **10** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **орфоэпия** | Сингармонизм. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр. Аваз һәм хәрефләрне аеру. Сузык авазлар.<br>Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре. Яңгырау һәм саңгырау, парлы һәм парсыз тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә генә хас булган [w], [гъ], [къ], [х], [ч]; [ж], [н], [h] авазлары.<br>*Е, ю, я* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу.Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы.Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе. *ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку. | |
| *2.2* | **Лексика** | Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Сүз ясалу үзенчәлекләре.<br>Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. Татар телендә исем һәм сыйфатның синтаксик бәйләнеш үзенчәлеге. Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану. Татар телендә алынма сүзләр.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану. Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану.<br>Сүз һәм аның мәгънәсе, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, алынма сүзләр, синоним,антоним, омонимнар.Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Искергән һәм яңа сүзләр. Бу белемнәрне гамәли сынап карау.<br>Татарча-русча, русча- татарча сүзлекләр, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, синонимнар сүзлеге, антонимнар сүзлеге, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге | **15** |
| *2.3* | **Сүз төзелеше** | Сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләү: тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә. Сүзне төзелеше буенча тикшерү.<br>Тамырдаш сүзләр турында төшенчә. Аларның синонимнардан һәм омонимнардан аермасы. Тамырдаш сүзләр һәм бер үк сүзнең төрле формалары.<br>Сүзләрнең дөрес язылышын тикшерү ысуллары: сүзнең формасын үзгәртү, тамырдаш сүзләр сайлау, орфографик сүзлек куллану. | **17** |
| *2.4* | **Морфоло-гия** | Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Предметны белдерүче сүзләр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр, аларның язылышы .<br>*Кем?Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Эш- хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Билгене белдерүче сүзләр.<br>Сүз төркемнәре турында төшенчә.<br>**Исем.** Мәгънәсе һәм кулланылышы. Берлек һәм күплек саннары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнегүләре.<br>**Фигыль.** Фигыльнең мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнары. -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк киләчәк заман хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышын гамәли үзләштерү. | **54** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Фигыльләргә морфологик анализ.<br>**Сыйфат.** Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре: гади(төп), чагыштыру, артыклык, кимлек. Чагыштыру дәрәҗәсендәге –рак, -рәк кушымчаларының һәм артыклык дәрәҗәсендәге кисәкчәләрнең дөрес язылышы.<br>**Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми күзаллау.Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.<br>**Кисәкчә**. *да, дә, та, тә* кисәкчәләрен *–да, -дә, -та, -тә* урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аерып таный белү ысуллары.Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.<br>**Бәйлекләр**, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Бәйлекләрне исемнәр һәм алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану. | |
| *2.5* | **Синтак-сис** | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую.<br>Сүз, сүзтезмә һәм җөмлә.  Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөрес әйтелеше.<br>Җөмлә. Әйтелү максатыннан чыгып, җөмләләрнең төрләре(хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы). Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).<br>Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү.<br>Җөмләдә сүз тәртибе. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә. | **20** |
| *2.6* | **Бәйләнеш ле сөйләм** | Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Өч-дүрт җөмләдән торган хикәя төзеп язу. Рәсем буенча кечкенә хикәя төзү. Шигырь, табышмак, мәкальләрне ятлап хәтер диктанты язу.<br>Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасын билгеләү, төп фикерен табу. Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.<br>Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү. Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.<br>Текст. Текстның темасын,  төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү. Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре.<br>Сөйләм этикасы белән таныштыру.<br>Сөйләм, аның тормыштагы  роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.<br>Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.<br>Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.<br>Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.<br>Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.<br>Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре. | **20** |
| **Барлыгы** | | | **136** |

**4 сыйныф**

| № | Бүлекләр-нең исеме | Укыту программасы бүлегенең төп эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| *2.* | | **Телне системалы өйрәнү** | |
| *2.1* | **Фонетика һәм орфоэпия** | Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Сингармонизм. Иҗек.<br>ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку.<br>Татар алфавиты: хәрефләрнең тәртибен һәм исемен яттан белү.<br>Сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.<br>Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Сүз ясалу үзенчәлекләре.<br>Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. | **7** |
| *2.2* | **Лексика** | Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану. Татар телендә алынма сүзләр.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану. Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану.<br>Сүз һәм аның мәгънәсе, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, алынма сүзләр, синоним,антоним, омонимнар.Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Искергән һәм яңа сүзләр. Бу белемнәрне гамәли сынап карау.<br>Татарча-русча, русча- татарча сүзлекләр, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, синонимнар сүзлеге, антонимнар сүзлеге, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге . | **8** |
| *2.3* | **Сүз төзелеше (морфемика)** | Сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләү: тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә. Сүзне төзелеше буенча тикшерү.<br>Тамырдаш сүзләр турында төшенчә. Аларның синонимнардан һәм омонимнардан аермасы. Тамырдаш сүзләр һәм бер үк сүзнең төрле формалары.<br>Сүзләрнең дөрес язылышын тикшерү ысуллары: сүзнең формасын үзгәртү, тамырдаш сүзләр сайлау, орфографик сүзлек куллану.<br>Ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең, ясалышы һәм дөрес язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау ,кушма сүзләрдә ь һәм ъ хәрефләренең язылыш кагыйдәләре, сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибе.<br>Сүз төзелешенә анализ. | **11** |
| *2.4* | **Морфоло-гия** | Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Предметны белдерүче сүзләр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр, аларның язылышы . *Кем?Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Эш- хәрәкәтне белдерүче сүзләр. Билгене белдерүче сүзләр.<br>Сүз төркемнәре турында төшенчә.<br>**Исем.** Мәгънәсе һәм кулланылышы. Берлек һәм күплек саннары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнегүләре.<br>**Фигыль.** Фигыльнең мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | **51** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнары. -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк киләчәк заман хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышын гамәли үзләштерү.<br>Фигыльләргә морфологик анализ.<br>**Сыйфат.** Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре: гади(төп), чагыштыру, артыклык, кимлек. Чагыштыру дәрәҗәсендәге –рак, -рәк кушымчаларының һәм артыклык дәрәҗәсендәге кисәкчәләрнең дөрес язылышы.<br>**Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми күзаллау.Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.<br>**Кисәкчә**. *да, дә, та, тә* кисәкчәләрен *–да, -дә, -та, -тә* урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аерып таный белү ысуллары.Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.<br>**Бәйлекләр**, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Бәйлекләрне исемнәр һәм алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану.<br>**Исем**<br>Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләренә күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы.<br>Баш килеш. Бу формада исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алулары. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе. Күплек сандагы исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы. Исемнәргә морфологик анализ.<br>**Фигыль**<br>Фигыль - катлаулы сүз төркеме. 4 нче сыйныфта 1-3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары.<br>Боерык фигыль. Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльне куллану, дөрес язу.<br>Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним Һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат бирү. Фигыльләргә морфологик анализ ясау күнегүләре.<br>**Сыйфат**<br>Сыйфат дәрәҗәләре. Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатның җөмләдәге роле (иярчен кисәкләр һәм хәбәр булып килүе).Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгнәдә кулланылуы.Антоним сыйфатлар, синоним сыйфатлар. Сыйфатларга морфологик анализ ясау күнегүләре.<br>**Алмашлык**<br>Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә. Алмашлык предметны яки билгене генә белдерми , ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була. Алмашлыкларның җөмләдәге роле. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә. Килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. . Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылышы.<br>**Сан**<br>Сан предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдәге роле. Кайбер сан төркемчәләре :микъдар саннары, тәртип саннары. Саннарга морфологик анализ.<br>**Рәвеш**<br>Рәвеш - мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.Рәвешләрнең җөмләдәге роле. Морфологик яктан - төрләнми. Ул ничек? кайчан? кая? кайда? никадәр? күпме ? кебек сорауларга җавап бирә. Эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме.<br>Сөйләмдә актив кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы.<br>**Кисәкчәләр**<br>Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә.<br>Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.<br>Кисәкчәләр сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана.Кисәкчәләр аерым торганда мәгънә белдерми. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була,һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә<br>**Бәйлекләр**. 1-3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Бәйлек-ярдәмче сүз, шуңа күрә, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр.Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла. | |
| *2.5* | **Синтак-сис** | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую.<br>Сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөрес әйтелеше.<br>Җөмлә. Әйтелү максатыннан чыгып, җөмләләрнең төрләре(хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы). Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).<br>Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү.<br>Җөмләдә сүз тәртибе. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә. Сүзтезмә. Сүз, сүзтезмә, җөмләнең охшаш һәм аермалы яклары. Сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне таный белү.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Ия белән хәбәр билгеләмәсе . Җыйнак һәм җәенке җөмләләр .Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. Аергычка билгеләмә бирү Һәм аның сыйфат белән белдерелүе .<br>Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр.Тиңдәш кисәкләр арасында ***һәм, я, да-дә, та-тә, ә, ләкин*** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. Эндәш сүзләртурында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.<br>Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2-3гади җөмлә булган кушма җөмләләр**.** Тезмә кушма җөмләләрдә ***һәм, ә, ләкин, әмма*** теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре. | **12** |
| *2.6* | **Орфогра-** | Орфография кагыйдәләре белән танышу: сүзләрдә э (е) хәрефенең язылышы; | **3** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **фия** | татар сүзләрендә о һәм ө хәрефләренең сүзләрнең беренче иҗегендә генә язылуы. Е, ю, я хәрефләре. Калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләре. Калын тартыклар [гъ], [къ] , аларны хәрефләр белән билгеләү. Сонор тартыклар [м], [н], [ң]. Тартыклар [в], [w], аларны хәрефләр белән билгеләү. | |
| *2.7* | **Бәйләнешле сөйләм** | Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Өч-дүрт җөмләдән торган хикәя төзеп язу. Рәсем буенча кечкенә хикәя төзү. Шигырь, табышмак, мәкальләрне ятлап хәтер диктанты язу.<br>Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасын билгеләү, төп фикерен табу. Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.<br>Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү. Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.<br>Текст. Текстның темасын, төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү.<br>Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре.<br>Сөйләм этикасы белән таныштыру.<br>Сөйләм, аның тормыштагы роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.<br>Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.<br>Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.<br>Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.<br>Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.<br>Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.<br>Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.<br>Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б. | **10** |
| **Барлыгы** | | | **102** |

Прошито, пронумеровано и
скреплено печатью
12 (двенадцать) листов
Директор: ________ /Мазитова Г.Т./